СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

19.05.2025 ел Алабуга шәһәре № 436

## Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Инвестицион үсеш бүлегенең штат расписаниесеннән түбәндәге вазифаны чыгарырга:

- баш белгеч - 1 штат берәмлеге.

1.2. Инфраструктура үсеше бүлегенең штат расписаниесеннән түбәндәге вазифаны чыгарырга:

- баш белгеч - 1 штат берәмлеге.

1.3. Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең штат расписаниесеннән түбәндәге вазифаны чыгарырга:

- бүлек башлыгы урынбасары - 1 штат берәмлеге.

1.3.1. Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең штат расписаниесенә түбәндәге вазифаны кертергә:

- баш белгеч - 2 штат берәмлеге.

1.4. Территориаль планлаштыру бүлегенең штат расписаниесенә түбәндәге вазифаны кертергә:

- баш белгеч - 1 штат берәмлеге.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының иң чик санын 76,25 штат берәмлеге күләмендә билгеләргә.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын кушымтада нигезендә яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасындагы үзгәрешләргә бәйле рәвешле, Алабуга муниципаль районының Финанс-

бюджет палатасына (Садыйкова Э.И.) Алабуга муниципаль районы бюджетына тиешле үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләргә.

5. Әлеге карар аны имзаланган көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Г.П. Баганов